КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 апрель г.Казань № 322

2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразын эшләү графигын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2021 – 2023 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразын эшләү графигын (алга таба – График, Фараз) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» дәүләт мәгълүмати-аналитик системасына (алга таба – Система) график нигезендә үз юнәлешләре буенча фараз күрсәткечләрен тапшыруны һәм кертүне тәэмин итәргә.

3. Тәкъдим итәргә:

Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, Татарстан Республикасында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы предприятиеләр һәм оешмаларга билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары соратулары буенча Фараз эшләү өчен кирәкле мәгълүмат җибәрергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына фараз күрсәткечләрен билгеләнгән График нигезендә Системага кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы предприятиеләр һәм оешмаларга җитештерү-финанс эшчәнлегенең фараз күрсәткечләрен Системага кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына мәгълүмат җибәргәндә һәм тапшырганда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгълүматны саклау режимы тәэмин ителергә тиеш дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин